**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 20 маендагы 1723 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 30 ноябрендәге 3755 номерлы «Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау (шул исәптән мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайтуга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирүгә үзгәрешләр кертү) турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексы, 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы федераль закон, 2025 елның 31 июлендәге 353-ФЗ номерлы «“Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”гы федераль законга һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон, 2024 елның 26 декабрендәге 486-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль закон, Казан шәһәре Башкарма комитетының 2011 елның 25 февралендәге 782 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында»гы карары нигезендә, Казан шәһәре Башкарма комитеты органнары эшчәнлегенең ачыклыгын тәэмин итү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 30 ноябрендәге 3755 номерлы «Капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау (шул исәптән мондый рөхсәтнең гамәлдә булу вакытын озайтуга бәйле рәвештә капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирүгә үзгәрешләр кертү) турында»гы карары белән расланган административ регламентка (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2024 елның 27 апрелендәге 1662 номерлы,

2025 елның 31 июлендәге 2518 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктның 1) пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1) физик затка эшмәкәрлек эшчәнлеген башкару белән бәйле булмаган максаттан бирелгән җир участокларында гараж төзү, реконструкцияләү яки Россия Федерациясенең 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы «Гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылыкны һәм яшелчәчелекне алып баруы һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында»гы федераль законы нигезендә билгеләнгән бакча участогында торак йорт, бакча йорты, хуҗалык корылмалары төзү, реконструкцияләү»;

1.2. 2.6.1 пунктның 6) пунктчасына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«6) Кодексның 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта, проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затлар әгъзалыгына нигезләнгән, үзидарәле оешма әгъзасы булып торган зат тарафыннан бирелгән һәм әлеге зат тарафыннан җәлеп ителгән проектның баш инженеры вазифасындагы архитектура-төзелеш проектлавын оештыручы белгеч тарафыннан Кодекс нигезендә расланган проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Кодексның 49 статьясындагы 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау»;

1.3. 2.6.8.1 пункттан 6) пунктчасын төшереп калдырырга;

1.4. 2.8.2 пунктның 7) пунктчасына түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Кодексның 51 статьясындагы 11.1-1 өлешендә каралган очракта, төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен Кодексның 51 статьясындагы 13 өлешендә каралган нигезләр белән беррәттән, төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигез булып территорияне планлаштыру проектында каралган территорияне планлаштырып үстерү чиратының проект документациясенә туры килмәве тора».

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең беренче урынбасары А.Р.Нигъмәтҗановка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**